Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2018 елның 12 нче феврале № 111

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге "Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында"гы Нигезләмә хакында" 64 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә, гамәлдәге законнар нормаларына тәңгәлләштерү максатларында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советының 2017 елның 4нче сентябрендәге 64нче номерлы карары белән расланган "Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында"гы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 11 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктчасын «сәяси партия» сүзеннән соң «билгеләнгән тәртиптә теркәлгән профсоюз» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Яңасала авылы, Үзәк ур., 1нче йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Шәпкә авылы, Клубная ур., 14нче йорт,

шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеге Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеге Советы рәисе И.Х. Шиһабиев